ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.11.2020 Олы Кайбыч ав. № 503

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Архитектура һәм шәһәр төзелеше өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 29 маендагы 254 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 декабрендәге 472-ФЗ номерлы, «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 13 июлендәге 202-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү турында» 2020 елның 13 мартындагы 279 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. «Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» 6 нчы кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Гомуми нигезләмәләр» 1 бүлегендә:

түбәндәге эчтәлекле 1.6. һәм 1.7 пунктлар өстәргә:

«1.6. Әлеге Регламентның гамәлдә булуы җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә кагылмый.

1.7. Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 12 өлешендә һәм 52 статьясындагы 3 өлешендә каралган очракларда капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү этапларына карата бирелергә мөмкин.»;

«Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» 2 бүлегендә:

- 2.4 пунктында «җиде көн» сүзләрен «биш эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

- 2.5 пунктчасында түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Проект декларациясенә үзгәрешләр кертү торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын төзү проектында каралган барлык йортларны файдалануга кертү турында белешмәләр урнашканнан соң таләп ителми.»;

- 2.6 пунктының 4,5 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясындагы 6_2 өлеше нигезендә капиталь төзелеш объекты мәйданын үзгәртү очракларыннан кала капиталь төзелеш объектының төзелешкә рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

5) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясындагы 6_2 өлеше нигезендә капиталь төзелеш объекты мәйданын үзгәртү очракларыннан кала проект документациясенең төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объекты параметрларының туры килмәве;»;

- 2.8 пунктында икенче баганада түбәндәге эчтәлекле бишенче абзац өстәргә:

«5) 63-ФЗ номерлы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнар таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) гариза һәм электрон документлар тапшыру.»;

- 2.9 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигез булып җир кишәрлегенә яисә җир кишәрлегендә урнашкан күчемсез мөлкәт объектына карата суд бәхәсе булу, шулай ук хокук саклау органнары тарафыннан күрсәтелгән күчемсез мөлкәт объектларына хокукны теркәү өчен нигез булган документларның законлылыгын тикшерү тора. Муниципаль хезмәт күрсәтү суд карары законлы көченә кергәнче йә документларны тикшерү тәмамланганчы туктатылып тора.»;

- 2.16 пунктта икенче өстәлдә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт, объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турындагы гаризада күрсәтелгән очракта, электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә тапшырыла.»;

«Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук күп функцияле үзәкләрдә, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең ерак эш урыннарында административ процедураларны башкару үзенчәлекләре» 3 бүлегендә:

- 3.5.1 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының 12 бүлегендә һәм 52 статьясының 3.3. бүлегендә каралган очракларда капиталь төзелеш объектларын

эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү турында яисә рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турында гариза бирелгән очракта, капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү этабына карата, әлеге Регламентның 2.5 пунктының 4, 5-11 бүлекләрендә күрсәтелгән документлар капиталь төзелеш объектын төзүнең, реконструкцияләүнең тиешле этабына караган өлешендә рәсмиләштерелә. Күрсәтелгән очракта капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү этабына карата объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү турындагы гаризада капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү этабына (булган очракта) карата элек тапшырылган рөхсәтләр турында белешмәләр күрсәтелә.».

2. «Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында булган белешмәләрне күрсәтү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» 14 нче кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктта:

7 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү турында» 2020 елның 13 мартындагы 279 номерлы карары («Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системаларын алып бару кагыйдәләре» белән бергә (алга таба - 279 номерлы Россия Федерациясе Карары));»;

8 абзацны гамәлдән чыккан дип санарга;

10 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2019 елның 12 августындагы 170 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы (алга таба - Устав);».

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары Э.Х. Заһидуллинага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров